КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 12 гыйнвар г.Казань № 3

Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм башка территорияләргә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына күченү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 21 октябрендәге 1876 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгын даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү

чараларын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 12 гыйнвар, 3 нче
карары белән расланды

Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм башка территорияләргә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына күченү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 21 октябрендәге 1876 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 21 октябрендәге 1876 номерлы карары) нигезендә даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына (алга таба – граждан) бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр (алга таба – сертификат, социаль түләүләр) бирү механизмын җайга сала.

1.2. Социаль түләү бирү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 21 октябрендәге 1876 номерлы карары белән расланган даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә ашыгыч массакүләм рәвештә килгән Херсон шәһәре һәм Херсон өлкәсенең бер өлеше халкына мөлкәт булдыру өчен бер тапкыр бирелә торган түләүләр һәм бирелә торган дәүләт торак сертификатлары нигезендә торак урыннар сатып алуга социаль түләүләр бирү чараларын финанс белән тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе субъектларына финанс ярдәме күрсәтү кагыйдәләренең 2 пункты нигезендә гомумән түбәндәге критерийларга җавап бирүче гражданнарга карата гамәлгә ашырыла:

гражаннар Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 21 октябрендәге б-3099 номерлы боерыгы белән расланган исемлек буенча Херсон өлкәсенең торак пунктларында) даими яшәү урыныннан мәҗбүри киткән һәм даими яшәү өчен Татарстан Республикасы территориясенә килгән;

гражданнар сертификат бирүгә гариза тапшырган.

1.3. Социаль түләү күләме Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган Россия Федерациясе буенча торак урынның 1 кв.метр гомуми мәйданы кыйммәте нормативының һәм ялгыз яшәүче гражданнар өчен – 33 кв.метр, ике кешедән торган гаиләләр өчен –

42 кв.метр һәм өч һәм аннан күбрәк кешедән торган гаиләләр өчен бер кешегә 18 әр кв.метр тәшкил иткән гомуми торак урын мәйданы белән тәэмин итү нормативының тапкырчыгышы буларак исәпләп чыгарыла.

1.4. Гражданнар социаль түләүдән файдаланып торак урын сатып алганда үз һәм (яки) заем акчасын файдаланырга хокуклы.

1.5. Социаль түләү гражданга бер тапкыр бирелә.

## II. Сертификатлар бирү тәртибе

2.1. Сертификат алу өчен граждан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган тәртиптә Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртиптә һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә (алга таба – КФҮ) яисә Министрлыкка, бу Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча сертификат алуга гариза (алга таба – гариза) тапшыра.

2.2. Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

гражданның, аның гаилә әгъзаларының шәхесен таныклый торган документлар (Россия Федерациясе гражданы паспорты яки шәхесне таныклый торган, шул исәптән Херсон өлкәсенең ачык хакимият органнары, Украина дәүләт хакимияте органнары, Украина җирле үзидарә органнары биргән һәм (яки) граждан хәлен раслый торган, Украина нотариуслары тарафыннан таныкланган башка документлар). Шул ук вакытта бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданның гаилә әгъзаларына ире (хатыны), балигъ булмаган балалары, 18 яше тулганга кадәр инвалид булган 18 яшьтән зуррак балалары, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда көндезге формада белем алучы 23 яшькә кадәр балалары, шулай ук ата-аналары һәм гражданның (иренең, хатынының) карамагында булган һәм алар белән бергә яши торган башка затлар кертеп карала;

гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә даими яшәү фактын раслый торган документ (яшәү урыны буенча теркәлү турында билгесе булган Россия Федерациясе гражданы паспорты, башка документлар яисә Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә күчемсез мөлкәткә милек хокукын раслый торган документ, әгәр мондый гражданның әлеге территорияләрдә даими яшәү фактын таныклый торган документы булмаган булса, гражданның Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә даими яшәү фактын раслый торган язма аңлатмасы теркәлә). Шул ук вакытта Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә даими яшәү фактын раслый торган документлары булмаган балигъ булмаган балаларның яшәү урыны

итеп аларның ата-аналары, уллыкка алучылары, опекуннары (попечительләре) һәм башка законлы вәкилләренең яшәү урыны танылa.

Украина телендә төзелгән документлар гади язма формада рәсмиләштерелә торган рус теленә тәрҗемә белән бирелә.

Гариза гражданның вәкиле аша бирелгән очракта, гаризага вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ теркәлә.

2.3. Гражданнарның 2022 елның 13 октябренә кадәр Херсон шәһәрендә яки Херсон өлкәсенең бер өлешендә яшәвен раслый торган документлары булмаган очракта, Министрлык, гариза һәм аның белән бергә бирелә торган документлар теркәлгән көннән соң килә торган өч эш көненнән дә соңга калмыйча, гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының Херсон шәһәре яки Херсон өлкәсенең бер өлеше территориясендә яшәвен раслау максаты белән Херсон өлкәсенең вәкаләтле органына рәсми сорау җибәрә.

2.4. Гражданның сертификат бирү өчен мөрәҗәгать итү көне – КФҮкә яки Министрлыкка кергән көнне теркәлә торган гаризаны һәм аның белән бергә бирелә торган документларны теркәү көне.

2.5. КФҮ гариза һәм аның белән бергә бирелә торган документлар теркәлгән көнне көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган гаризаны һәм аның белән бергә бирелә торган документларны, мондый документларны кәгазь чыганактан башка, Министрлыкка җибәрә.

2.6. Министрлык гариза һәм аның белән бергә бирелә торган документлар теркәлгән көннән биш эш көне эчендә, ә бу Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә рәсми сорау җибәрелгән очракта – гариза һәм аның белән бергә бирелә торган документлар теркәлгән көннән 15 эш көне эчендә гаризаны һәм аның белән бергә бирелә торган документларны карап тикшерә һәм сертификат бирү турында йә бу Тәртипнең 2.10 пунктында каралган нигезләр буенча сертификат бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Министрлык бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә гражданга гаризада күрсәтелгән ысул белән Министрлык тарафыннан раслаган форма буенча кабул ителгән карар турында хәбәрнамә җибәрә. Сертификат бирүдән баш тарту турындагы хәбәрнамәдә баш тартуның сәбәпләре күрсәтелә.

2.7. Министрлык, «Территорияләрне үстерү фонды» гавами-хокукый компаниясе (алга таба – Фонд) тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, «ТКХ реформасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан (алга таба – система) файдаланып, сертификатлар бирү турында карар кабул ителгән гражданнарның гаризаларын эшкәртә һәм, гаризаларны теркәү датасыннан чыгып, бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән гражданнар исемлеген (алга таба – исемлек) төзи.

Министрлык атна саен исемлекне раслый һәм, исемлек расланган көннән киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, аны система аша Фондка тапшыра.

2.8. Социаль түләүнең күләме Министрлык тарафыннан исемлек расланган датага карата Министрлык тарафыннан исәпләп чыгарыла.

2.9. Гражданга Фонд тарафыннан билгеләнгән форма буенча кәгазь рәвештә сертификат бирү КФҮ яки Министрлык тарафыннан сертификат бирү турында

карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән ысул белән гамәлгә ашырыла. Сертификат бирү турында белешмә системага кертелә.

2.10. Сертификат бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез була:

гражданның бу Тәртипнең 1.2 пунктында каралган критерийларга туры килмәве;

гаризаның һәм (яки) аның белән бергә бирелә торган документларның бу Тәртипнең 2.1 һәм 2.2 пунктларында каралган таләпләргә туры килмәве (шул исәптән тулысынча тутырылмавы);

граждан тарафыннан бу Тәртипнең 2.2 пунктындагы икенче, дүртенче, бишенче абзацларында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы;

гаризада һәм аның белән бергә бирелә торган документларда дөрес булмаган белешмәнең булуы;

гаризадагы һәм аның белән бергә бирелә торган документлардагы белешмәләр арасында каршылыкларның (төгәлсезлекләрнең) ачыклануы;

социаль түләүнең Россия Федерациясендәге башка субъектта алынуы.

Граждан, сертификат бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигез булган сәбәпләрне бетергәннән соң, КФҮгә яки Министрлыкка кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

## III. Социаль түләү бирү тәртибе

3.1. Социаль түләү социаль түләүләр бирү чараларын финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасына бирелгән Фондның финанс ярдәме исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3.2. Социаль түләү түбәндәге шартларны үтәгәндә бирелә:

торак урыннар Татарстан Республикасы территориясендә беренчел яки икенчел торак базарларында физик һәм (яки) юридик (бер яки берничә) затлардан сатып алынган;

сатып алынган торак урын (торак урыннар) (алга таба – торак урын) Россия Федерациясе Торак кодексының 15 һәм 16 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, даими яшәү өчен сайланган торак пункт шартларына карата, шул исәптән авыл җирлегендә (каралты корылмаларын исәпкә алып) төзекләндерелгән;

сатып алынган торак урынның гомуми мәйданы гаиләнең һәр әгъзасына исәпләгәндә Россия Федерациясе Торак кодексының 50 статьясындагы 5 өлеше нигезендә билгеләнгән торак урын мәйданының исәпкә алу нормасыннан ким булмаска тиеш;

гражданның сертификаттан файдаланып сатып алынган торак урынга милек хокукы билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынган;

бер яки берничә сертификат нигезендә берничә гражданга бирелергә тиешле социаль түләүләрне файдаланган очракта, торак урын әлеге гражданнарның өлешле милкенә сатып алынырга тиеш, бу вакытта мондый торак урынга гомуми өлешле милек хокукындагы өлешләр күләме социаль түләүләр һәм (яки) башка чыганаклар акчасы исәбеннән торак урын сатып алучы затларның һәркайсы тарафыннан түләнә торган сатып алу бәясенең бер өлеше күләменә пропорциональ булырга тиеш;

бер сертификат буенча социаль түләү акчасыннан файдаланып, берничә сату-сатып алу шартнамәсе нигезендә берничә торак урын (торак урынга уртак өлешле милек хокукында өлешләр) сатып алынган очракта, социаль түләү әлеге шартнамәләр буенча түләү өчен бер үк вакытта башкарыла;

граждан тарафыннан бирелгән торак урыннар сату-сатып алу шартнамәләре буенча түләү башкарылганнан соң социаль түләү акчасының файдаланылмый калган өлеше кайтарыла.

3.3. Социаль түләүне алу өчен граждан, сертификаттан файдаланып сатып алынган торак урынга милек хокукы билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Министрлык тарафыннан расланган форма буенча социаль түләүне күчерү турында КФҮнә яки Министрлыкка гариза тапшыра.

Социаль түләүне күчерү турындагы гаризага Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан гражданның милек хокукы дәүләт теркәвенә алынган торак урынны сату-сатып алу шартнамәсенең күчермәсе теркәлә.

Ике һәм аннан күбрәк торак урыннар сатып алынганда, бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән документлар берьюлы тапшырылырга тиеш.

Социаль түләүне күчерү турындагы гариза гражданның вәкиле аша бирелгән очракта, мондый гаризага вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ теркәлергә тиеш.

Билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган документларның күчермәләре төп нөсхәләрне күрсәтеп тапшырыла.

Граждан үзе тапшырган документлардагы белешмәнең дөреслеге өчен җавап бирә.

3.4. Министрлык бу Тәртипнең 3.3 пунктында күрсәтелгән документларны алган көннән җиде эш көне эчендә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә гражданның сатып алынган торак урынына милек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында белешмә соратып ала.

Граждан әлеге белешмәне үз инициативасы белән күрсәтергә хокуклы.

3.5. Министрлык социаль түләүне күчерү турында гариза алган көннән 15 эш көне эчендә әлеге гаризаны, аның белән бергә бирелә торган документларны һәм бу Тәртипнең 3.4 пункты нигезендә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә кергән документларны тикшерүне гамәлгә ашыра һәм әлеге документлар бу Тәртипнең 3.2 пунктында билгеләнгән шартларга туры килгәндә торак урынны сатучы исәбенә социаль түләүне күчерә.

3.6. Әгәр бу Тәртипнең 3.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән шартнамәдә билгеләнгән торак урынның факттагы кыйммәте сертификатта күрсәтелгән социаль түләү күләменнән кимрәк булса, мондый түләү торак урынның факттагы кыйммәте күләмендә күчерелә.

Әгәр бу Тәртипнең 3.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән шартнамәдә билгеләнгән торак урынның факттагы кыйммәте сертификатта күрсәтелгән социаль түләү күләменнән күбрәк булса, мондый түләү сертификатта күрсәтелгән күләмдә күчерелә.

Бер сертификат буенча социаль түләү акчасыннан файдаланып, берничә сату-сатып алу шартнамәсе нигезендә берничә торак урын (торак урынга уртак өлешле

милек хокукында өлешләр) сатып алынган очракта, социаль түләү әлеге шартнамәләр буенча түләү өчен бер үк вакытта башкарыла.

3.7. Бу Тәртипнең 3.3 пунктында күрсәтелгән документлар тулы булмаган комплектта тапшырылган һәм (яки) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документлар тапшырылган һәм (яки) бу Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән шартларның үтәлмәве ачыкланган һәм (яки) документларда тулы яки дөрес булмаган белешмә билгеле булган очракта, Министрлык социаль түләүне күчерү турындагы гариза алынган көннән иң күбе 10 эш көне эчендә гражданга рәсми сорау алынган көннән биш эш көне эчендә аларны бу Тәртипнең таләпләренә туры китерергә кирәк булу турында рәсми сорау (алга таба – сорау) җибәрә. Рәсми сорау гражданга расписка белән тапшырылырга, тапшыру турында хәбәрнамә бирелә торган заказлы хат итеп яки гражданның электрон почтасына электрон рәвештә җибәрелергә мөмкин.

Министрлык гражданнан документлар комплектын кабат алган көннән 10 эш көне эчендә гражданнан торак урынны сатучы исәбенә социаль түләүне күчерә йә гражданга бу Тәртипнең 3.8 пунктында каралган нигезләрдә социаль түләүләрне күчерүдән баш тарта һәм Министрлык тарафыннан расланган формада хәбәрнамә җибәрә. Хәбәрнамәдә әлеге баш тартуның сәбәбе күрсәтелергә тиеш.

3.8. Бер тапкыр бирелә торган түләү бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Тәртипнең 3.3 пунктында каралган тулы булмаган документларны тулы комплектта тапшырмау;

Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документларны тапшыру;

бу Тәртипнең 3.2 пунктында күрсәтелгән шартларны үтәмәү.

документларда тулы яки дөрес булмаган белешмә булу;

бу Тәртипнең 3.7 пунктындагы беренче абзацында каралган срокта җитешсезлекләрне бетермәү.

3.9. Граждан тарафыннан торак урын сату-сатып алу шартнамәсе өзелгән очракта, бирелгән социаль түләү акчасы граждан тарафыннан Министрлыкның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетына күчерелә.

Әгәр гражданга социаль түләү бирелгәннән соң социаль түләү бирү өчен нигез булган дөрес белешмә бирелмәү факты ачыкланган булса, Министрлык әлеге факт ачыклаган көннән биш эш көне эчендә гражданга, алга таба Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерү өчен, тапшыру турында хәбәрнамә теркәлгән заказлы хат итеп, Министрлыкның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетына социаль түләүне ирекле рәвештә кайтару турында таләп җибәрә.

Бу пунктның беренче һәм икенче абзацлары нигезендә акча ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

## IV. Гражданга элек бирелгән сертификатны юкка чыгару һәм яңа сертификат бирү тәртибе

4.1. Граждан тарафыннан Россия Федерациясенең башка субъектында бирел-

гән сертификат нигезендә социаль түләүне гамәлгә ашыру турында гариза бирелгән очракта, мондый гариза бер үк вакытта яңа сертификат алуга һәм Россия Федерациясенең башка субъектында бирелгән сертификаттан баш тартуга гариза булып санала.

Гамәлдән чыгарыла торган сертификатка алмашка яңа сертификат бирелгәндә гамәлдән чыгарыла торган сертификатка кертелгән гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының бу Тәртипнең 1.2 пунктындагы икенче абзацында каралган критерийларга, шул исәптән бу Тәртипнең 2.3 пунктында каралган тәртиптә туры килү-килмәвен тикшерү гамәлгә ашырылмый һәм әлеге гражданнарга карата 2.2 пунктта күрсәтелгән документларны кабат тапшыру таләп ителми.

Элек бирелгән сертификат гражданга яңа сертификат бирү турында белешмә Министрлык тарафыннан системага кертелгән вакыттан алып гамәлдән чыгарыла.

4.2. Министрлык Россия Федерациясенең башка субъектында бирелгән сертификат нигезендә социаль түләүне гамәлгә ашыру турында гариза алынган көннән өч эш көне эчендә, системадан файдаланып, элек гражданга сертификат биргән Россия Федерациясе субъектына гражданга элек бирелгән сертификатны гамәлдән чыгару турында мәгълүмат бирә.

4.3. Сертификат алган граждан тарафыннан Россия Федерациясенең башка субъектын даими яшәү урыны буларак сайлау турында карар кабул ителү хакында һәм гражданга Россия Федерациясенең башка субъектында яңа сертификат бирү турында Министрлыкка мәгълүмат кергәндә, Министрлык мондый мәгълүмат кергән көннән өч эш көне эчендә гражданны исемлектән төшереп калдыра.

4.4. Сертификатның хуҗасы вафат булган очракта, гаиләнең балигъ булган башка әгъзаларының нотариаль таныкланган ышанычнамәсе нигезендә эш итүче аның гаилә әгъзасы Министрлыкка, үлем турындагы таныклыкның күчермәсен теркәп, элек бирелгән сертификатны гамәлдән чыгару һәм яңа сертификат бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итә. Яңа сертификат бирү турында карар кабул ителгәндә социаль түләүнең күләмен исәпләп чыгару яңа сертификат бирү датасына гамәлдә булган Россия Федерациясе буенча торак урынның 1 кв.метр гомуми мәйданы кыйммәте нормативыннан һәм сертификат бирү датасына гаиләнең факттагы составыннан чыгып башкарыла.

Сертификат хуҗасының гаилә әгъзасы вафат булган очракта, сертификатның хуҗасы, үлү турындагы таныклыкның күчермәсен теркәп, элек бирелгән сертификатны гамәлдән чыгару һәм яңа сертификат бирү турында гариза белән Министрлыкка мөрәҗәгать итә. Бу вакытта яңа сертификат бирү һәм социаль түләү күләмен исәпләп чыгару, хуҗасы вафат булган очракта, яңа сертификат бирү өчен каралган тәртиптә башкарыла.

Сертификат хуҗасы үзенең гаилә әгъзалары белән яңадан кушылган очракта, сертификат хуҗасы элек бирелгән сертификатны юкка чыгару һәм яңа сертификат бирү турында гариза һәм бу Тәртипнең 2.2 пунктында каралган документлар белән Министрлыкка мөрәҗәгать итә. Бу вакытта яңа сертификат бирү бу Тәртипнең 2.3 – 2.10 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла, ә социаль түләүнең күләмен исәпләп чыгару бу Тәртипнең 1.3 пункты нигезендә башкарыла.

Бу пунктта каралган очракларда, элек бирелгән сертификат Министрлык тарафыннан гражданга яңа сертификат бирү турында белешмә системага кертелгәннән соң юкка чыгарыла.

## V. Контрольдә тотуны гамәлгә ашыру

Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гражданнарга социаль түләү бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.